# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ТУТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2020 ел, 1 октябрь №7

**Тутай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” гы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Тутай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге Советы карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге Советының 2016 елның 12 февралендәге “Тутай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә” 21 номерлы карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8.3 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;”;

2) 19.1 пунктның 4 пунктчасында "(булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен" сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Тутай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Тутай авыл**
**җирлеге Башлыгы**
**Тутай авыл җирлеге**
**Советы Рәисе** **Н.М. Насретдинова**